Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«30» ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Олы Шилнә авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2025 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү , ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, илтеп җиткерү, махсус техника хезмәтләре күрсәтү);
- урамнарны яктырту җайланмасы (сатып алу, китерү, урнаштыру, электр җиһазлары, комплектлау элементлары, урамнарны яктырту баганалары һәм кабель сатып алу, китерү, урнаштыру, урамнарны яктыртуны монтажлау);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру (балалар өчен уен, спорт җиһазлары, кибетләр, вазоннар, коймалар, хуҗалык блогы балалар мәйданчыгын каплау өчен ком сатып алу);
- тротуарларны төзү, ремонтлау (тротуарны төзекләндерү эшләрен башкару);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч проектлау һәм төзү);
- традицион Күмү урыннарын ремонтлау, коймаларны кору, төзекләндерү (зиратны төзекләндерү, зират коймасын сатып алу һәм урнаштыру);
- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычларын, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, су сыйфаты күрсәткечләрен билгеләү, яшелләндерү).

2. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г.Даутов